# Малайларга, кызларга@.RU

## Баш мөхәррир сүзе

Кояшлы сентябрь таңы безне кабат бергә җыйды. Мәктәпләрдә һәр бала көтеп алган, кызыклы вакыйгаларга бай булган яңа уку елы башланды. Күңелләрдә сөенеч, йөзләрдә шатлыклы елмаю балкый. Яңа уку елы һәркемгә шатлык - сөенечләр, бары "4"ле һәм "5"леләре генә алып килсен. Бәйрәм белән сезне, дуслар! Яңа уку елында уңышлар, яхшы билгеләр, саулык - сәламәтлек, тырышлык, бәхетләр телибез!
Үзенең борчу-мәшәкатьләре, кайгылы да, шатлыклы да көннәре белән көтеп алган уку елының тәүге ае үтеп тә китте. Барлык мөгаллимнәр инде уку алды мәшәкатьләренә күмелде. Балалар да түземсезлек белән мәктәп ишекләрен ачып керде, сыйныфташлары, дуслары белән очрашып, мавыктыргыч яңа дәресләргә, сыйныфтан тыш чараларга, түгәрәкләргә ашкынып, китап-дәфтәрләрен, уку кирәк-яракларын барлап, укуга кереште, тәүге белгеләрен алып өлгерде.
Мәктәп тә безне яңа үзгәрешләр белән каршы алды.
Җәй - укытучы өчен ял гына түгел, үткәннәргә нәтиҗә ясап, яңа планнар кору вакыты да. Бүгенге көндә кызыклы сораулар базасын булдыру өстендә эшлим. Сез дә бу эштә миңа ярдәм итә аласыз.
Кыскасы, барысы да сезгә уңайлы булсын өчен эшләнә, дусларым.
Яңа уку елы яңа идеяләргә, уңышларга бай ел булсын, укучыларыбыз безне тирән белемнәре, яхшы тәрбия сыйфатлары белән сөендерсен!
Көзнең күркәм, ямьле бәйрәмнәренең берсе - Укытучылар көне. Хөрмәтле коллегалар! Сезне чын күңелдән һөнәри бәйрәмебез белән котлыйм. Сезгә ныклы сәламәтлек, эшегездә, гаиләгездә тынычлык теләп кала

***Татар теле һәм әдәбияты укытучысы***
***Шәяхмәтова Г.М***

# *“Яратам мин алтын көзләрне...!*



***Матур гадәт буенча һәр уку елы башында укучылар алтын көзгә, җәйге истәлекләргә, Республика көненә багышланган иҗади эшләр, рәсемнәр конкурсында катнашалар. Бу эшләр эссе, инша, шигри формада яки кроссворд, чайнворд рәвешендә дә булырга мөмкин. Бүген бездә кунакта 2”А” сыйныф укучылары.***

“...Менә көз җитте. Агачлар кызыл, сары төскә керә башлады. Кошлар җылы якларга очырга җыеналар. Көннәр суына. Балалар мәктәпкә йөри башлады”

Ильясова Алия.

***“Көз җитте”***

Тышта – көз. Кояш җәйге кебек җылытмый. Кошлар җылы якларга юл тоталар. Агачларның яфраклары саргаеп һәм кызарып матур күренәләр. Яңгыр ява башлады.”

Әхмәтҗанов Азамат.

***“Алтын көз”***

Менә безнең көтеп алган алтын көз дә килеп җитте. Урманда, барлык тирә-якта агачлар сары яфракларга төренде. Сары яфраклар кыштырдап җиргә коелып төшәләр.

Менә балалар да көзнең матурлыгын күрергә урманга килгәннәр. Алар җиргә коелып төшкән сары яфракларга, табигатьнең шундый матурлыгына исләре китеп карап торалар. Менә алар шатланып гөмбә җыеп йөриләр. Үзләренең күргәннәрен алар башка балалар белән дә уртаклашырлар.

Аязгулов Эмиль.

***“Көзге эшләр”***

Көз җиткәч бөтен дөнья үзгәрә башлый. Әкияттәгедәй табигать төрле төскә керә. Мин яратам көзне.

Без көз көне бөтен гаиләбез белән бакча эшләре эшлибез. Җимешләрне җыябыз, агачларны тәрбиялибез, яңа агачлар утыртабыз , бәрәңге алабыз, йорт алларын җыештырабыз.

Миңа бик ошый әтием белән әниемә эшләшергә.

Юнысов Ришат.

***“Алтын көз”***

Менә алтын көз дә килеп җитте. Уңышларны җыеп алырга җыена бар халык. Комбайннар иген суга. Көз – эшнең иң күп вакыты. Яз утыртылган бөтен үсемлекләрдән яз уңыш алына һәм кышкылыкка запас ясала.

Морзагилдин Ранис.

# *Лицейда – “Әтиләр атналыгы”*



Минем әтием Хәмидуллин Илдус Марат улы Авыргазы районының Мостафа авылында 1976 елда дөньяга килә. Гаиләдә алты бала була. Әти-әнисе балаларын тәртипле, уңган, тәртипле итеп үстерәләр. Үсеп буй җиткәч, армия сафларына алына әтием. Авыр Чечен сугышында катнашырга туры килә. Бик күп яралар алып, күрсәткән батырлыырлары өчен “Батырлык” медале белән бүләкләнеп кайта солдат.

Күпме күрсә дә, бөгелмәде-сыгылмады ул. Яратып йөргән кызы белән тормыш корып, матур итеп дөнья көтеп яши. Гаиләдә ике бала үсә: апам Әлия һәм мин, Рената. Әнием белән бергә өзелеп яратып, җил-яңгыр тидерми үстерәләр алар безне.

Эшендә дә хөрмәт итәләр әтиемне. Талбазы авылы почтасында ул иң уңган, тырыш хезмәткәрләрнең берсе. Барысы өчен дә киң киң күңелле. Ярдәмчел, гел елмаеп торган егетне яратмаган кеше юктыр.

Безнең өчен әти иң яхшы дус, киңәшче, якын кешебез. Яраткан әтиемә киләсе көннәрдә ныклы сәләмәтлек, бәхет, элеге кебек саф, изге күңелле булып калуын телим.

Кызы Рената Хәмидуллина, 5а сыйныф укучысы.



### *“Әти – дөньяда иң якын кешем”*

Минем әтием безнең гаиләнең иң ышанычлы таянычы. Ул бик таләпчан, тырыш, намуслы кеше. Аның кулыннан килмәгән эше юк. Безнең белән уйнарга да вакыт таба. Кичләрен безгә кызыклы китаплар укый. Без әтием белән туп уйныйбыз, кышын чаңгыда, тимераякта йөрибез.

Эшендә дә әтиемне ихтирам итәләр. Ул Авыргазы авыл хуҗалыгы идарәсендә инженер булып эшли. Яхшы эшләгәне өчен аңа “Авыл хуҗалыгының атказанган эшчесе” дигән мактаулы исем бирделәр.

Мин әтиемне бик яратам. Аның белән горурланам, йөзенә кызыллык китермәскә тырышам.

Наилә Ильясова, 5а сыйныф укучысы.

## *“Кадерле кешем”*



Минем әтиемнең исеме – Газим. Аңа 47 яшь. Ул шофер булып эшли. Мин аны бик яратам, аның белән горурланам.

“Егет кешегә 70 төрле һөнәр дә аз” дип әйтелгән халык мәкале тап минем әтиемә туры килә. Ул агач эшләрен яратып башкара. Аның эшләгән утыргычлары , өстәлләре исең китәрлек. Ул гына да түгел, караган бал кортлары биргән балы телеңне йотарлык.

Минем әтиемнең куллары алтын дисәң дә була, чөнки күп кешенең машиналары ватылса әтиемә ярдәм сорап киләләр. Ул берсен дә кире какмый, ремонтлап, җайга салып җибәрә.

Ул агач, тимер эшләре белән генә тукталып калмый, бакчада яшелчә-җимеш үстерергә дә ярата. Бигрәк тә көзләрен гөмбә җыя, аларны тәмле итеп тозлый. Минем әтием гөмбә генә тозламый, ул бит балык тотарга да бик ярата, аннары инде аларны тазартып, эшкә кертеп, төрле тәмләткечләр кушып тозлый.

Әтием бер эштән дә куркып тормый, һәр бер эшне яратып, җиренә җиткереп башкара.

Әмма аның иң яраткны, кадерләгәне, күз нуры – мин. Мин дә аны бик яратам, хөрмәтлим. Аны башка бер кешегә дә алмаштырмыйм. Әгәр дә әтиләрне сайлап алырга кушсалар , мин тик үз әтиемне генә сайлар идем.

Биккулова Эльвина, 5б сыйныф укучысы.

...

Минем әтием Котлыбаев Айрат Марат улы менә 23 ел инде балаларга тәрбия һәм белем бирә. Ул Көязбаш мәктәбендә тарих фәнен укыта. Аның һөнәре – иң изге һөнәрләрнең берсе булып санала.

Минем әтиемнең кулыннан килмәгән эше юк. Ул төрле уен коралларында уйный, агачтан юнып миңа уенчыклар ясап бирә, җырлар – шигырьләр дә яза. Менә бер шигырен язып үтәсем килә.



Әти белән эштән кайтып киләм
Каты карда аяк тавышы.
“Бүгенә, ди, эшләр бетте, балам,
Арыган йөзе, моңсу карашы.

Җылы өйдә әни безне көтә,
Күптән инде пешкән ашы да.
Кайнар ашның тәмле исләрен,
Сизәм ара ерак булса да.

Тыныч кына әти атлый юлдан,
Ә мин киләм арттан шаярып,
Кызык сөйләп күргән кинолардан,
Әтиемнең күңелен күтәреп.

Еллар үтте, чыкмый һаман истән
Балачакның озын юллары.
Кайткан кебек әти белән эштән,
Көткән кебек әни ашлары...

Бүген үзем эштән кайтып киләм,
Кызым килә кырдан шаярып.
Ул да шулай кайтыр берчак, беләм,
Ә баласы килер ияреп.

Әтием минем ягымлы да, сөйкемле дә , һәряклап талант остасы. Мәктәптә оештырылган төрле чараларда үзенең язган җырларын да өйрәтә. Балаларга.Матурлыкны күрә белә ,укычыларын да яхшылыкка омтылырга өнди.

Мин әтием белән горурланам. Әтиемә дә, әниемә дә ныклы сәламәтлек, озын гомер һәм эшендә зур уңышлар телим.

Котлыбаева Айлина, 6б сыйныф укучысы.

***

Рәйфә Бәхтигәрәева

## *“Әтигә”*

Без бәхетле булып үссен өчен
Гомер буе янып- көйдең син.
Жәлләмичә, әти, көчеңне
Эшнең авырына түздең син.
Һәрчакта да безгә терәк булдың
Беребезне читкә какмадың.
Җидебезне бердәй якын күреп
Гомер буе, әти, якладың.
Нинди заман килде җир йөзенә
Үткәннәрне исләп юксынма.
Үз туганың бүген дошман төсле
Вөждан, намус оча упкынга.
Рәнҗемисең, әти, син аларга
Үзәгеңә үтә сүзләре.
Кайчан гына синең ярдәмеңә
Мохтаж иде алар үзләре.
Гелән генә бит син ярсып чыгып
Хаклык, гаделлекне яуладың,
Гелән безне тормыш давылында
Күз карасы кебек сакладың.
Онытыйк, әти, авырлыкны,
Онытыйк кеше сүзләрен,
Тормыш дәрьясында адашмаска
Илһам бирә һәрбер сүзләрең.

## *“Җәйге истәлекләр”*

...Җәй – минем иң яраткан мизгелем. Аның һәрбер көне үзенчәлекле. Менә шул көннәрнең берсе турында язып китәсем килә.

Безнең өебез урман каршында урнашкан, шуның өчен җәйге иртә бик ямьле. Иртән торып тышка чыксаң, агачлар артыннан кояш чыкканы бик матур итеп күренә, урманда кошлар сайрый, һавның сафлыгын сүзләр белән генә әйтеп бетерерлек түгел.

Менә шундый матурлыкта җәйнең бер көне башлана. Шушы көнне без гаиләбез белән урманга җиләк җыярга барырга булдык. Җыендык та, машинага утырып киттек. Урманда җиләкнең күплеге! Ятып җыйсаң да җыеп бетмәслек. Шуның өчен без алган савытларыбызны тиз генә тутырып, төш вакытына кайтып та җиттек. Әни җиләктән варенье ясады һәм җиләк бәлеше пешерде. Мин шул арада дусларым белән момтоциклда йөреп кайттым.



Җәйнең иртәсе матур булса, кичләре тагы да ямьлерәк. Кояш баеганда күк йөзенең төрле төсләргә керүе генә ни тора!

Шушы матурлыкка сокланып җәйнең бер көне үтеп тә китте.

Хабибуллин Ринат, 9б сыйныф укучысы.

***

...Быелгы җәй бик күңелле үтте. Без гаиләбез белән Кара диңгез буена ял итәргә бардык. Җәйнең иң нык истә калган матур бер көне – Ял вакытында Абхазия республикасына экскурсиягә бару.

Иртән без автобуска утырдык. Беренче тукталыш Гагры шәһәрендә булды. Патша заманында төзелгән колоннаданы күрдек, искиткеч матур табигать кочагында фотосессия үткәрдек. Диңгез буйлап барып Пицунда шәһәренә җиттек, анда диңгездә су коендык. Алга таба юл Кавказ тауларыны алып менде. Таулар арасында бик матур зәп-зәңгәр сулы күл бар. Легенда буенча ,шул күлнең суы белән битеңне юсаң – яшәрәсең.

Киләсе тукталыш таудагы умарталыкта булды. Абхаз бал кортлары кешене чакмыйлар икән. Бал тәмләп карадык. Таулардагы иң матур ,әкияттәге кебек гүзәл күлләрнең берсе – Рица. Ул күл диңгез өстендһән 950 метр биеклектә урнашкан. Кичкә таба Яңа Афон пещерасына кердек. Ул 6 залдан тора, озынлыгы- 5 километр.



...Төнгә каршы алып-талып кайтып кердек. Бу көннең истәлекләре күңелдә озак сакланыр...

Хәмидуллина Әлия, 9б сыйныф укучысы.

***

... Җәйнең истәлекле бер көне 16 июль булды. Иртәнге сәгать сигездә торып, җыенып без Уфага киттек, безне алда гүзәл Испания иле көтә! Сәгать унбердә аэропортка килеп җиттек, бөтен таможняларны үтеп, көтү залында утырдык.

Сәгать бер дә самолетка утырдык. Әкренләп кенә һавага күтәрелә башладык, күтәрелгәч бөтенебез шатланып, кул чаптык. Минем өч тапкыр самолетта очканым булса да, чакк кына куркыныч булды. Аста бик матур яланнар, урманнар, күлләр, өйләр күренеп тора иде. Төшкәч, отельгә килеп җиткәч, тиз генә җыендык та, диңгезгә су керергә киттек. Суы бик чиста, матур, зәңгәр иде, комы ялтырап тора.



Бик шәп булды бу көн. Иртән генә без үзебезнең өебездә булсак, кич инде чит илдә, отельдә! Испания - искиткеч ил! Без сине онытмабыз!

Әблиева Айгөл , 9б сыйныф укучысы.

***

...Безнең көтеп алган җәйге каникуллар җитте. Барлык укучылар шатланышып, озын ялга киттеләр.

Җәйге каникулда мин авылда ,нәнәйләрдә булдым. Минем бер авылда ике нәнй, шуның өчен әле бер нәнәйдә, әле икенчесендә ял иттем. Ял итеп кенә ятмадым, бакча эшләрендә булыштым, тәмле итеп ашарга әзерләдем, өй җыештырдым. Кич көне кызлар белән урамга чыктык. Бала-чага тавышыннан авыл шау-гөр килеп тора.



Җәй айлары бик эссе булды, су керергә йөредек. Безнең авыл кырында зур буа бар. Барлык бала-чага чыр-чу килеп, шунда рәхәтләнеп су керә.

Шулай итеп ,матур җәйге каникуллар үтеп китте. Мин нәнәйләргә рәхмәт әйтеп, кайтып киттем. Алда безне уку, сыйныфташларым көтә!

Шаһизиганова Гүзәл, 9б сыйныф укучысы.

... Менә көз килде, җәйге каникуллар артта калды. Май азагында нәнәй янына авылга кайттым, анда чүп утадым, су сиптем. Авылдагы кызлар белән су керергә йөредек, су җылы һәм чиста иде.

Июль урталарында без гаилә белән Аккүлгә бардык. Җәйге каникулның шул көне хәтердә нык калды. Ул көн бик эссе иде, көн буе без күлдә су кердек һәм ял иттек. Соңыдан су буендагы урманга бардык. Анда төз каеннар, имәннәр, һуш исле чәчәкләр үсә. Кайткач, каникулның соңгы көннәренә кадәр өйдә булдым. Уку елы башланды, мәктәпне сагынып укырга килдек.

Жданова Диана, 9б сыйныф укучысы.



* Хикәяләрдә авторларның стиль үзенчәлеге сакланды.

## *“Безнең кунак”*

***Алтын көз шагыйрьләрне дә, җырчыларны да илһамландыра. Якташ язучылар иҗатында көз темасы еш искә алына. Бүген бездә кунакта шагыйрә һәм җырчы Халидә Гайнуллина. 9б сыйныф укучысы Ләйсән Гайнуллина әнисе турында менә болай дип язды:***



“Минем сезгә әнием турында бераз сөйлисем килә. Ул Минебай авылында туып үсә Гаиләдә 5 бала тәрбияләнә– ике ул һәм өч кыз . Әниемнең балачагы бик бәхетле үткән. Кечкенәдән шигырьләр яза башлый. Мәктәпне тәмамлагач “Культпроссвет” техникумына укырга керә, аны тәмамлагач Талбазы мәдәният йортына эшкә урнаша. Тырышып эшләгән яшь белгеч инде берничә елдан мәдәният йортының директоры вазыйфасын башкара. Кичәләр, концертлар өчен сценарийлар яза. Авыл мәдәният йорты бинасы чыгышлар өчен яраксыз дип табылгач, коллективын район мәдәният йортына күчерәләр. Шул дәвердә әнием шигырьләр язуын дәвам итә, алар районыбызда “Ватан юлы” гәзитендә ештан-еш басылып чыгалар.

Әниемнең шигырьләрен коллегасы укып чыккач, аларга көй языр өчен этисенә күрсәтергә тәкъдим итә. Шулай итеп, дөньяга әниемнең беренче җыры барлыкка килә, ул “Онытмам авылымны” дип атала. Талбазы авылына 250 еллыгына багышлап әнием “ Авыргазым – туган ягым” исемле шигырь яза. Кырмыскалы районынында яшәүче композитор Фәнир Фәизов шигырьне көйгә сала. Бераз вакыттан соң әниемнең ризалыгы белән бу җыр Кырмыскалы районының гимнына әверелә”.



Ләйсән Гайнуллина, 9б сыйныф укучысы

## *“Алтын көз”*



Көзләр җитте, агач яфраклары
Шыптырдашып җиргә коела
Күңел моңсу, никтер йөрәк әрни
Басыла алмас кебек тоела.
Сирәк-ара салкын җилләр исә
Алтын көз китәргә ашыга.
Сары-кызыл ачгач яфраклары
Бөтерелеп оча каршыма.

Урманнарда тыныч, тик аяк астында
Кыштырдаган яфрак тавышы.
Анда-монда кош тавышы гына
Боза урмандагы тынлыкны.
Килер инде салкын буранлы кыш
Күмеп бөтен дөньяны карга.
Күл елгалар туңып, тынып калыр
Тирән йокыга китәр бар да.